КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 24 август г.Казань № 1009

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2022 – 2023 елларда Татарстан Республикасында сәнәгать предприятиеләре хезмәткәрләрен һөнәри укытуны һәм аларга өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру турында» 2022 ел, 23 март, 257 нче карары белән расланган 2022 – 2023 елларда эш бирүчеләрнең сәнәгать предприятиеләре хезмәткәрләрен һөнәри укытуны һәм аларга өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру чыгымнарын финанс белән тәэмин итүгә (каплауга) субсидия бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2022 – 2023 елларда Татарстан Республикасында сәнәгать предприятиеләре хезмәткәрләрен һөнәри укытуны һәм аларга өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру турында» 2022 ел, 23 март, 257 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 7 декабрь, 1300 нче; 2023 ел, 18 февраль, 157 нче; 2023 ел, 24 апрель, 522 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган 2022 – 2023 елларда эш бирүчеләрнең сәнәгать предприятиеләре хезмәткәрләрен һөнәри укытуны һәм аларга өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру чыгымнарын финанс белән тәэмин итүгә (каплауга) субсидия бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

8 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8. Субсидия сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган айның 1нче көненнән дә иртәрәк булмаган датага карата түбәндәге таләпләргә туры килә торган эш бирүчеләргә бирелә:»;

9 пунктның унбишенче абзацы үз көчен югалткан дип танырга;

түбәндәге эчтәлекле 9.1 пункт өстәргә:

«9.1. Заявкаларны карап тикшерү нәтиҗәләре турында, эш бирүчеләр һәм сайлап алу нәтиҗәләре турында, шул исәптән эш бирүчеләр белән төзелгән килешүләр турында мәгълүмат – файдалану мөмкинлеге чикләнгән мәгълүмат, ул бердәм порталда һәм халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенең рәсми сайтында урнаштырылмый.»;

10 пунктта:

бишенче абзацта «сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган айның 1нче көненә» сүзләрен «сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган айның 1нче көненнән дә иртәрәк булмаган датага» сүзләренә алмаштырырга;

унынчы абзацта «сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган айның 1нче көненә» сүзләрен «сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган айның 1нче көненнән дә иртәрәк булмаган датага» сүзләренә алмаштырырга;

уналтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«эш бирүченең офшор компаниясе, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булып тормавын раслый торган, җитәкче тарафыннан имза куелган, мөһер сугылган (булганда) белешмә кәгазе.»;

16 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

23 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«23. Министрлык субсидия алучының субсидия бирү шартларын һәм тәртибен (шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү өлешендә) үтәвен тикшерүне гамәлгә ашыра.

Дәүләт финанс контроле органнары субсидия алучы тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә субсидия бирү тәртибенең һәм шартларының үтәлешен тикшерә.

Субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешүне мониторинглау килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешүдән һәм субсидия бирү нәтиҗәсен алу буенча тиешле чара төгәлләнү факты чагылдырыла торган вакыйгалардан (контроль нокта) чыгып, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм формалар буенча үткәрелә.»;

25 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«тулы күләмдә – субсидия алучы тарафыннан субсидия биргәндә билгеләнгән шартлар бозылган очракта, субсидия алучы тарафыннан субсидия алу өчен дөрес булмаган мәгълүмат һәм (яки) документлар тапшырылу факты, шул исәптән халыкны эш белән тәэмин итү үзәге, Министрлык, дәүләт финанс контроле органы үткәргән тикшерүләр буенча ачыкланган фактлар билгеләнгән очракта;».

2. Бу карарның 1 пунктындагы бишенче, алтынчы һәм уникенче абзацы гамәле 2023 елның 6 апреленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин